ЧӘРШӘМБЕ
31 МАРТ
1943 ел.
№ 71 (6793)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕКНЕ ТИКШЕРҮ

Социалистик авыл хуҗалыгыбыз быел илгә, фронтка авыл хуҗалыгы продуктларының һәр төрен үткән елга караганда күбрәк бирергә, хезмәт ияләренең, Кызыл Армиянең азыкка карата, промышленностьның чималга карата булган ихтиаҗын тулысынча канәгатьләндерергә тиеш. Бу — бөек һәм катлаулы бурыч. Һәм аны үтәү өчен көрәш — барлык колхозчыларның, МТС, совхоз эшчеләренең, авыл хуҗалыгы белгечләренең, авылдагы партияле һәм партиясез большевикларның намус эше.

1943 нче елда югары иген уңышы алуга ирешү күп кенә дәрәҗәдә колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның язгы чәчүгә ничек әзерләнүләренә һәм аны ничек үткәрүләренә бәйләнгән. Менә шуңа күрә дә, колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның язгы чәчүне үрнәк әзерлек белән каршылауларына ирешү — чәчү вакытына кадәр калган чорда үзәк мәсьәләләрнең берсе, иң җаваплы бурычларның берсе. ВКП(б) Өлкә Комитеты карары нигезендә, 1 нче апрельдән 10 нчы апрельгә кадәр булган чорда республикабыздагы барлык МТС ларның, совхозларның һәм колхозларның язгы чәчүгә әзерлеген тикшерү үткәреләчәк.

Тикшерү язгы чәчүгә әзерлекнең барлык якларын үз эченә алырга тиеш. Тикшерү комиссияләренә МТС һәм совхозларның иң яхшы тракторчыларын, бригадирларын, механикларын, алдынгы һәм тәҗрибәле колхозчыларны, ярышучы МТС, совхоз һәм колхоз вәкилләрен, шулай ук урындагы партия, совет һәм комсомол работникларын, белгечләрне киң күләмдә тартырга кирәк. Тикшерү зур оешканлык белән үткәрелергә тиеш.

Тракторларның һәм тагылма инвентарьның чын-чыннан яхшы әзерләнгән булуы язгы эшнең уңышын хәл итүдә зур роль уйный. МТС һәм совхозлар буенча тикшерү үткәрүче комиссияләр үзләренең төп игътибарларын һәрбер тракторга, машинага ясалган ремонтның сыйфатына юнәлдерергә, һәрбер тракторны нагрузка белән эшләтеп карарга тиешләр. Ремонтның сыйфатын тикшерү нәтиҗәсендә ачылган бөтен җитешсезлекләрне, шул исәптән иң кечкенә кимчелекләрне дә кичекмәстән бетерүгә ирешү — МТС, совхоз директорларының, политбүлек начальникларының җаваплы бурычы. Бурыч — һәрбер тракторның, машинаның кыр эшләрен башлауга тулысынча әзер булуына, чәчү вакытында тулы нагрузка белән нормаль эшләрлек хәлгә китерелүенә ирешүдән гыйбарәт.

Машинадан тулы файдалану бары тик аны тулы әзерлекле кадр кулына тапшырганда гына мөмкин. Шуңа күрә дә тикшерү комиссияләре эшнең бу тармагына зур әһәмият бирергә, МТС яки совхозның тракторчылар, бригадирлар, механиклар һәм прицепщиклар белән тәэмин ителү-ителмәвен җентекләп карарга тиешләр. Бу кадрларның аерым рәвештә һәрберсенең квалификация дәрәҗәсен тикшерергә кирәк. Белеме, тәҗрибәсе җитәрлек дип табылмаган кешеләр өчен бик тизлек белән өстәмә рәвештә уку-өйрәнү, ә бу кадрлар җитмәгән урыннарда кичекмәстән кыска сроклы яңа курслар оештырылырга тиеш.

МТС һәм совхозның язгы чәчүгә әзерлеген тикшерү нәтиҗәләрен эшчеләрнең, инженер-техник работникларның гомуми җыелышларында өйрәнеп, комиссияләр тарафыннан ачылган барлык җитешсезлекләрне иң кыска вакыт эчендә бетерү буенча конкрет чаралар күрелергә тиеш.

Язгы чәчүгә әзерлекне тикшерү республикабыздагы барлык колхозларның икенче хәрби язны үрнәк төстә каршы алуларына ирешүдә зур этәргеч булырга тиеш. Тикшерү комиссияләре игътибарыннан язгы чәчүгә әзерлекнең бер генә тармагы да төшеп калмасын. Колхоз кирәкле күләмдә, кондицияле чәчү орлыгы белән үзен тәэмин иткәнме, моның өчен мөмкин булган бөтен ресурсларны ничек хәрәкәткә китергән, инвентаре тулы әзерлектәме, атларны, мөгезле эре терлекләрне әзерләү ничек тора, язгы чәчү вакытына эш планы төзелгәнме, һәрбер колхозчыга чәчү вакытында аның кайда, кем булып эшләве билгелеме, хезмәтне исәпкә алу, нормалар билгеләү дөрес оештырылганмы — менә бу мәсьәләләргә тикшерү вакытында тулы һәм ачык җавап алынырга тиеш.

Тикшерү колхозларда язгы чәчүгә әзерлекнең теге яки бу тармагында зур гына җитешсезлекләрне ачачак. Тикшерүнең нәтиҗәләре һәм ачылган барлык җитешсезлекләрне бетерү буенча конкрет чаралар колхозчыларның гомуми җыелышларында куелырга тиеш. Партия, совет, комсомол оешмалары чәчүгә әзерлекне тикшерүдә ачылган бөтен кимчелекләрне тиз арада бетерү буенча практик чаралар күрергә һәм үз колхозларының чәчүне тулы әзерлек белән каршы алуларына һәм большевикларча үткәрүләренә ирешергә тиешләр.

ВКП(б) райкомнары, район башкарма комитетлары язгы чәчүгә әзерлекне тикшерү эшен оештыруга зур игътибар бирергә тиешләр. Бу эшнең уңышлы чыгуы, аны урыннарда ничек оештыруга бәйләнгән. Менә шуңа күрә дә, ВКП(б) Өлкә Комитеты барлык райкомнарга районның партия, совет, комсомол оешмаларында, җир органнарында эшләүче җаваплы работникларны язгы чәчүгә әзерлекне тикшерүне оештыру өчен колхозларга җибәрергә тәкъдим итте. Тикшерүнең йомгаклары нигезендә ВКП(б) райкомнары, район башкарма комитетлары алдынгы колхозларның тәҗрибәләрен башкаларга күчерү буенча, артта баручы колхозларга бик тиз булышу буенча практик чаралар билгеләргә тиешләр.

Язгы чәчүгә үрнәк төстә әзерләнгән МТС лар, колхозлар, совхозлар, бригадалар, звенолар һәм аерым колхозчылар, МТС һәм совхоз эшчеләре өчен район һәм өлкә газеталарында «Почет тактасы» оештырыла. Һәрбер МТС, совхоз, колхоз, бригада һәм звено, колхозчы, МТС, совхоз эшчесе үзенең мактаулы урынны алуы өчен большевикларча көрәшергә тиеш.

МТС, совхоз һәм колхозларның язгы чәчүгә әзерлеген тикшерү — зур һәм мөһим эш. Аны совет җәмәгатьчелегенең киң катнашы белән үткәрик! Республикабыздагы һәрбер МТС ның, совхозның һәм колхозның язгы чәчүгә тулы әзерлеген тәэмин итик!

Совет Информбюросыннан

30 нчы МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

30 нчы мартка каршы төндә фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

☆ Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр алган позицияләрендә ныгыдылар һәм разведка алып бардылар. Н-че часть сугышчылары дошманның бер артиллерия батареясын һәм бер ротага якын пехотасын юк иттеләр. 6 пулемет, 18 автомат, берничә дистә винтовка һәм бер склад сугыш припаслары кулга төшерелде. Немецларның 17 бомбардировщигы, 3 истребитель ярдәме белән, безнең гаскәрләр урнашкан җирне бомбага тотарга маташканнар иде. Командиры иптәш Шумихин булган частьның зенитчиклары ут ачтылар һәм берничә минут эчендә дошманның 3 самолетын атып төшерделәр. Немецларның калган самолетлары тәртипсез рәвештә берничә бомба ташладылар һәм бик тиз качтылар.

☆ Белый шәһәреннән көньяктарак Н-че берләшмәнең частьлары, дошманның каты каршылыгын җиңеп, алга киттеләр һәм берничә халык яши торган пунктны алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда 300 ләп гитлерчы кырылды. Дошманның 2 орудиесе, 1 миномет батареясы һәм 1 сугыш припаслары склады безнең кулга төшерелде.

☆ Төньяк Донецның урта агымы районында немец автоматчиклары Н-че частьның позициясенә атака ясарга маташканнар иде. Безнең сугышчылар гитлерчыларны башлангыч позицияләренә алып ташладылар һәм аларга зур югалтулар китерделәр. Икенче бер участокта артиллерия уты белән дошманның күп санлы тупланган пехотасы таркатылды, 2 миномет батареясының уты бастырылды һәм бер самоход орудиесе юк ителде.

☆ Кубаньда дошманның бер рота пехотасы, 7 танк һәм 3 бронемашина ярдәме белән, безнең оборонабызга разведка ясарга маташкан иде. Н-че часть подразделениеләре артиллерия һәм миномет уты белән дошманны таркаттылар, немецларның 4 орудиесен җимерделәр. Безнең очучылар һава сугышларында немецларның 9 самолетын атып төшерделәр. Шуның өстенә зенитчиклар уты белән дошманның 2 самолеты юк ителде.

☆ Сталино өлкәсе районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецлар гарнизонын тар-мар иткән. 100 дән артык гитлерчы үтерелгән, шулардан 15 е офицерлар. Ровен өлкәсе партизаннары отряды дошманның җанлы көчләре һәм техникасы төялгән тимер юл эшелонын юлдан чыгарган. Бер паровоз һәм 10 вагон җимерелгән. Һәлакәт нәтиҗәсендә 120 гитлерчы үлгән һәм яраланган.

☆ Немецларның 15 нче пехота дивизиясенең 88 нче полкындагы 8 нче ротадан плен алынган унтер-офицер Герман Крайз түбәндәгеләрне сөйләде: «Безнең дивизия февральнең икенче яртысында Франциядән килде. Мин инде көнчыгыш фронтта сугышларда катнаштым һәм ике тапкыр яраландым. Франциядән Россиягә килгән солдатларның настроениесе начар. Монда тимер тәрәгә караганда агач тәрәне яулап алу өчен ышаныч зуррак икәнне алар бик яхшы беләләр. Бу ачы хакыйкатьне солдатлар төрле яклап кабатлыйлар. Моннан бер ел элек көнбатышта икенче фронт төзелү мөмкинлегенә ышанучы аз иде. Хәзер, күп кенә немец дивизияләрен Франциядән көнчыгышка күчерү уңае белән, күпчелек солдатлар һәм офицерлар, англичаннар һәм америкалылар бу хәлдән файдаланырлар дип уйлыйлар».

☆ Югославия партизаннары Невесине шәһәренә килү юлларында дошманның 300 солдатын һәм офицерын юк иткәннәр һәм 118 итальянны плен алганнар. Оккупантларның 10 минометын, 25 пулеметын, бик күп сугыш припасларын һәм төрле хәрби милекләрен кулга төшергәннәр. Коница шәһәре янында һәм Неретва елгасы районында булган бик каты сугышларда патриотлар итальян-немец оккупантларына зур югалтулар китергәннәр.

30 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

30 нчы мартта фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

Кара диңгездә безнең корабльләр дошманның 2.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

☆ 29 нчы мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 10 га якын танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 7 кыр зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар. Баренц диңгезендә безнең авиациябез дошманның барлыгы 6.000 тонна авырлыктагы 3 транспортын батырды.

☆ Төньяк Донецның урта агымы районында бер участокта көн буена дошманга каршы бик каты сугышлар барды. Немецларның бер танк дивизиясе, безнең оборонаны өзәргә уйлап, һөҗүмгә күчкән иде. Дошман үз дивизиясенең хәрәкәтләренә көчле артиллерия уты һәм авиациянең зур көчләре белән булышлык итте. Генерал-майор Тихонов командалыгындагы безнең гвардия берләшмәсе дошманның һөҗүмен нык торып каршы алды һәм гитлерчыларның барлык атакаларын кире кайтарды. Безнең сугышчылар үзләре берничә тапкыр контратакага күчтеләр һәм дошманны авыр югалтуларга дучар иттеләр. Тулы булмаган саннарга караганда, немецларның 10 самоход орудиесе юк ителде, 22 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Сугыш кырында немецлар үз солдатларының һәм офицерларының 500 гә якын үле гәүдәләрен калдырдылар. Һава сугышларында безнең очучыларыбыз тарафыннан, шулай ук артиллерия һәм мылтык-пулемет уты белән сугыш кыры өстендә дошманның 18 самолеты бәреп төшерелде.

☆ Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр аерым участокларда актив сугыш хәрәкәтләре алып бардылар. Н-че часть сугышчылары немецларны халык яши торган бер пункттан бәреп чыгардылар. Бу пункт өчен булган сугышларда 200 гә якын гитлерчы юк ителде. Икенче бер участокта Н-че берләшмә частьлары бер урында немецларның оборонасына барып керделәр һәм көчле итеп ныгытылган, халык яши торган бер пунктны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

☆ Белый шәһәреннән көньякта безнең гаскәрләр дошман оборонасына разведка ясадылар һәм аерым участокларда җирле әһәмияте булган сугышлар алып бардылар. Совет сугышчылары, томан булудан файдаланып, яшеренеп, дошманның бер терәк пунктына барып чыктылар һәм андагы гитлерчыларга атака ясадылар. Немецлар, сугыш кырында үз солдатларының һәм офицерларының 100 дән артык үле гәүдәләрен калдырып, бу пункттан чигенделәр.

☆ Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды 16 нчы мартка каршы төндә халык яши торган ике пункттагы немец гарнизоннарын тар-мар иткән. Партизаннар берничә дистә гитлерчыны кырганнар һәм 66 кешене плен алганнар. Бер миномет, 3 пулемет, 87 винтовка, күп кенә миналар һәм патроннар кулга төшерелгән. Партизаннарның икенче бер отряды дошманның 2 тимер юл эшелонын юлдан чыгарган. Партизаннарның актив хәрәкәте нәтиҗәсендә, Орел өлкәсе аркылы үтә торган гаять әһәмиятле тимер юл кимендә ике атнага стройдан чыгарылган.

☆ Үтерелгән бер немец солдатыннан бер хат табылды. Хатны Марктредвица шәһәреннән аның кыз туганы язган. Хатта болай диелә: «... Россиядә бик кыен икәнлекне Франц язган иде. Язуын, ләкин аның да шундый ук бәхетсезлеккә очравы мөмкинлеге хәтта минем төшемә дә кермәгән иде. Кичә минем янымда Францның иптәше булды һәм бөгенесен сөйләп бирде. Ротада 180 кешедән бары 12 кеше калган. Франц бердән-бер исән калган унтер-офицер булган. Иртә белән сәгать 5 тә алар чигенер өчен кузгалганнар, ә бер сәгатьтән инде Франц үтерелгән. Марктердвицадан инде күп кешеләр һәлак булды. Кайбер семьялардан икешәр кеше үтерелде... Тагын нәрсә булыр икән?»

☆ Смоленск өлкәсе, Сычевка шәһәре кешләре Мария Калинина, Наталья Удовенко һәм Евдокия Орловалар түбәндәгеләрне сөйләделәр: «Немец-фашист кабахәтләр Юшино авылында гражданнар халкы өчен концентрация лагеры ясадылар. Гитлерчылар бу лагерьга Сычевка шәһәренең һәм тирә-як авылларның бик күп гражданнарын яптылар. Ябылганнар арасында күп кенә яшь үсмерләр һәм балалы хатыннар бар иде. Тоткыннарны коточкыч төстә газапладылар. Лагерьда җәза камерасы бар иде. Аннан беркем дә диярлек исән кайтмады. Анда немец бандитлар үзләренең корбаннарын газапладылар һәм җәзаладылар. Атып үтерүләр булмаган көн бик сирәк булды. 15 нче январьда гына да 36 кешене атып үтерделәр. Икенче бер вакытны без утырган 2 камерада бер көн эчендә 28 хатынны аттылар. Бер ай эчендә фашистлар 200 дән артык кешене, шул исәптән күп кенә балаларны үтерделәр».

Сталинградны
ТӨЗЕКЛӘНДЕРИК

Тимер юлчылар актив булышалр

Юдино депосында һәм вагоннар ремонтлау участогында эшләүче комсомолецлар, шулай ук союздан тыш яшьләр оккупантлар коллыгыннан азат ителгән районнардагы тимер юл челтәрен аякка бастыруга эш белән ярдәм итәләр. Бу патриотик хәрәкәткә депода һәм ремонт участогында эшләүче карт производствочылар да кушылдылар. Ремонтчылар Сталинград тимер юл узелына ярдәм итү ун көнлеге игълан иттеләр һәм эш вакытыннан тыш төрле инструментлар, җиһазлар әзерләү эшенә керештеләр.

Тимерчеләрдән Филиппов, Кузнецов, Молюк һәм башка иптәшләр 5 көн эчендә 60 данә зубил, 100 данә бороток, 40 данә гайка ачкычы һәм башка бик күп инструментлар эшләделәр. Тимер юлчылар мәктәбендә укучылар ял көнендә үткәрелгән өмәдә 30 данә зубил ясадылар.

Тимерчеләрдән Кузнецов, Ушакєв һәм Петрова иптәшләр 120 рессор ремонтладылар. Кою цехы эшчеләре бик әһәмиятле булган 300 данә деталь койдылар. Шушылар өстенә, станциянең вагончылары 150 данә подшипник, 30 данә плоскозуб, 10 берләштерү краны әзерләделәр. Паровозлар өчен запас частьлар ясадылар, автотормоз җиһазлары булдырдылар.

Комсомолец иптәш Сапарин һава тигезләүче бер тәҗрибә өстәленә ремонт ясады.

Н. ГУСЕВ

100 НОМЕРЛЫ КОММУТАТОР

Партоешма секретаре урынбасары иптәш Ставер булган Н-че заводның баш энергетика бүлегенә караган цехларда һәм участокларда эшләүчеләр 28 нче мартта, ял көне стахановчы вахтага басып, эш көненнән килгән хезмәт хакын тулысынча Сталинградка ярдәм фондына тапшырдылар.

Заводның энергетиклары Сталинград шәһәренең Дзержинский районындагы предприятиеләрнең берсен җиһазлауга хәзерлек эшләре алып баралар. Начальнигы иптәш Тюнеев булган цех коллективы барлык җиһазлары белән 26 кубовиклы компрессор хәзерли.

Начальнигы иптәш Кобызев булган цех барлык җиһазлары белән 100 ваттлы радиоустановка хәзерли. Цехның телефон станциясе 100 номерлы коммутатор хәзерләп җибәрү йөкләмәсен алды. Хәзер телефон аппаратларын ремонтлау эше бара. Электромонтер иптәш Чернышев, эш вакытыннан соң калып, телефон аппаратларын ремонтлый һәм яхшы күрсәткечләр бирә.

Бүлек һәм бүлеккә караган участоклар югарыда күрсәтелгән җиһазларны 1 нче апрельдә заводтан җибәреләчәк эшелонга өлгертү өчен көрәшәләр.

КОЛХОЗЧЫЛАР БҮЛӘГЕ

ТЫМЫТЫК. 29 март. (Телефон буенча). «Уразман» колхозы членнары 28 центнер бәрәңге, 10 сарык, 7 кәҗә, 1.140 сум акча, 929 данә йомырка, 580 литр сөт җыеп, Сталинградка ярдәм фондына тапшырдылар.

Колхоз члены, ватан сугышы инвалиды иптәш М. Солтанов бер сарык, Ширияздан бабай бер сарык, 50 килограмм бәрәңге бирделәр.

«Ишкай» колхозы членнары 5 тире, 220 йомырка, 240 литр сөт, 7 сарык бирделәр.

Соңгы бер-ике көн эчендә Сталинград хезмәт ияләренә җибәрү өчен район буенча барлыгы 74 данә тире, 130 баш сарык, 3.797 литр сөт, 7.615 данә йомырка, 42 баш ат, 67 данә мөгезле эре терлек, 64 баш дуңгыз, 43 сабан, 22.615 сум акча җыеп тапшырылды.

КОМСОМОЛ ТОРМЫШЫ

Яшьләр, фронт таләбен үтәгез!

БҮГЕН КИЧӘГЕГӘ КАРАГАНДА, ИРТӘГӘ БҮГЕНГЕДӘН ЯХШЫРАК ЭШЛӘГЕЗ! ЮГАРЫ УҢЫШ ӨЧЕН КӨРӘШТӘ АЛДЫНГЫЛАР САФЫНДА БУЛЫГЫЗ!

Киләсе ел уңышының хәле авыл яшьләренең агротехник белемнәрне яхшы үзләштереп, колхоз производствосына нык булышлык итүләренә бәйләнгән. Бу хәзерге вакытта, күп кенә яшь кадрларның җитәкче постларга күтәрелгәнен искә алганда, бигрәк тә шулай. Алар киңәшчеләр генә түгел, бәлки үзләренең үрнәкләрендә ничек эшләргә кирәклеген күрсәтүче дә булырга тиешләр.

1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү планы комсомол оешмасына да югары уңыш өчен көрәш программасын билгеләде. Һәрбер комсомолец үзенең эшен шушы программаны тормышка ашыру, аны колхозчы массага аңлатудан башларга тиеш. Югары уңыш өчен көрәш башта бригадада һәм звенода башлана. Димәк, комсомолецларның урыны шунда. Ул аларны оештыру һәм нығыту өчен бөтен көчен бирергә тиеш. Тарту көчләрен тәрбияләү, алардан файдалануда, орлыклык ашлыкны саклау һәм аны чәчүгә әзерләүдә, язгы чәчүне агротехник срокларда үткәрүдә комсомол көрәшче булсын. Тәҗрибәле колхозчылар һәм агрономнар белән комсомолецларның дуслыгы практик эштә нығысын.

Газетаның бу битендә Апас районы, «КИМ» колхозы комсомолецларының шушы бурычларны үтәү өстендә ничек эшләүләре турында языла. Кече Болгаер авылының яшь бригадирларының, чәчүчеләренең, сөрүчеләренең, ферма мөдире һәм агитаторларының ничек эшләүләре турында сөйләнә. Билгеле, язгы чәчүгә әзерлекне уңышлы тәгәлләп килүче колхозның комсомолецлары һәм союздан тыш яшьләре алдагы көннәрдә дә, кызу сабан өстендә дә шулай яхшы эшләрләр һәм авыл хуҗалыгын үстерү өчен көрәштә алдынгы сафта булырлар.

Чәчүлек орлык әзер

Чәчүлек орлык—ул колхозның алтын фонды. Шуңар күрә дә без аны бик җентекләп, кадерләп саклыйбыз. Төрле культуралар буенча чәчүлекләр салына торган келәтләрне яхшылап сыладык, кар-буран үтмәслек хәлгә китердек. Орлыклык участоклардагы ашлыкның күбесен көннәр коры вакытта ук сугып, чистартып, шул келәтләргә салып куйдык. Орлык чистартуда комсомолкалардан Сәкинә Фәйзуллина һәм Сания Сабирова иптәшләр колхозга зур булышлык күрсәттеләр. Һәркөнне бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләделәр. Нәтиҗәдә без бодай, солы, карабодай, борчак, ясмык орлыкларын чистартуны 1 нче январьга ук тәгәлләп, кондициягә җиткердек. Алар лабораториядә тикшерелеп кайттылар инде.

Без орлыкларның сакланышын нык күзәтәбез. Орлык ашлыгы салынган келәтләрне һәркөнне тикшереп карап торабыз. Дымлылыкны күзәтү приборлары, иген корткычларына каршы капканнар куйдык. Шушы арада комсомолецлар орлыкның тишелешен тагын бер кат тикшереп карарга әзерләнәләр.

Тары орлыгы чистарту өчен җилгәргечебез юк инде. Аны да булдырып, орлык чистартуны тәгәлләдек инде. Шулай итеп, безнең чәчү орлыгыбыз әзер. Аларны яхшы саклау өчен нык көрәшәбез.

Х. БИКМӨХӘМЕТОВА,
колхозның завхозы.

ТРАКТОРЧЫ КЫЗ

Шәмсиҗамал Сабирова ватан сугышы көннәрендә комсомол сафына керде.

— Комсомолка дигән исемем бар, эшем шуны акласын,—ди ул һәм шулай эшли дә. Үзган ел, беренче ел буларак тракторда эшләде. Быел инде аның тәҗрибәсе бар. Кышкы көннәрдә дә ремонтта катнашып, үзенең белемен арттырды. Сабан сөргәндә, кирәксезгә туктап тормас өчен үзенең тракторын кыр эшләренә яхшылап әзерләде.

С. САДРЕТДИНОВ.

Атлар көр булсын

Язгы чәчү өчен кирәкле булган авыл хуҗалыгы машиналарыбыз барысы да төзек. Сбруйларыбыз да җитәрлек. Ләкин атлар арасында аерым тәрбиягә мохтаҗ булганнары бар. Мин бу турыда ат караучы иптәшләр белән сөйләштем. Ун елдан бирле ат караучы булып эшләүче тәҗрибәле иптәш Камалетдинов:

— Мин 10 баш ат тәрбиялим. Кич белән саламны чылатып, он сибеп башак бирәм. Сәгать 9 ларда чыгып, атларның ашарларына өстәп керәм. 12 сәгатьтә тагын бер кат аларның хәлләрен беләм. Иртә белән атлар азыкларын ашап бетергәч, абзарларны чистарта башлыйм. Тик менә, безнең кайбер колхозчылар эш вакытында атны яхшылап карап йөртмиләр. Аларны кыйныйлар, шуңа күрә атлар ябыгалар,—ди.

Без ат караучылар белән бер фикергә килдек. Һәркөнне атларның нинди хәлдә эшкә китүләрен һәм ничек кайтуларын нык күзәтергә һәм кимчелекләр булганда, шунда ук правлениегә хәбәр итәргә булдык.

Колхозда атларны җәберләп, кыйнап йөртүчеләр дә бар иде. Без андый кешеләрне җыелышта нык тәнкыйтьләдек, атлар белән яхшы могамәләдә булуларын таләп иттек.

Аерым көннәрдә ат абзарларына налет ясау, андагы тәртипне тикшерү өчен комсомолецлардан берничә кеше билгеләдек.

Р. БАҺАВЕТДИНОВА,
Башлангыч комсомол оешмасы секретаре.

БИРЕДӘ КОМСОМОЛЕЦЛАР ЭШЛИ

4 нче бригада үзенең оешканлыгы, эшчәнлеге белән күпләргә билгеле. Аның һәрбер эше тәртипле.

Менә аның атлары урнашкан абзар. Ул чиста һәм җылы. Атлар вакытында яхшы итеп тәрбияләнәләр. Аларны ашату сәгатьләре билгеле. Кич 6 һәм 9 сәгатьтә, төнге 12 дә, иртәнге 4 тә үткәрелә.

Шуннан ерак та түгел бригаданың авыл хуҗалыгы инвентарьлары һәм сбруйлар саклана. Анда керү белән язгы чәчүгә әзерләнеп куелган чәчү машинасы, сабан, тырмаларны күрәсең. Ә күршедәге амбарда камытлар, постромкалар, дилбегәләр, йөгәннәр һәм сабан калакларын күрәсең.

Бу бригадада чәчү вакытында кемнең кайда эшләргә тиешлеге билгеләнгән. Атлар аерым колхозчыларга беркетелгәннәр. Бу бригадада эшнең шундый тәртибен күргәч, биредә комсомолец егет эшләвен беләсең һәм шуңа горурланып куясың. Колхоз председателе иптәш Абдуллин да:

— Бу комсомолец Исмәгыйлов бригадасы була. Ул инде язгы чәчүгә тулысынча әзер,—дип куя.

ФЕРМА

Кече Болгаер авылының югары очында колхозның терлекчелек абзарлардан, кечерәк кенә йортлардан торган бу фермада төнлә дә, көндез дә кызу эш кайный. Иртәрәк барсаң, терлек торакларын чистарту вакытына туры киләсең, соңрак инде яшь терлекләрне туйдыру вакытын очратасың. Биредә бәрәннәр матурлар һәм чисталар.

Яшь бәрәннәр караучы иптәш Гыйниятова сарыклар фермасында 10 елдан бирле эшли. Аның тәрбиясендәге бәрәннәр барысы да таза-сәламәт булып үсәләр.

Ферма терлекләренең тору урыннары аерым-аерым итеп бүленгән. Язгы-көзге бәрәннәр һәм бозаулар өчен дә аерым урыннар әзерләнгән. Алар төнлә җылы абзарларда куналар, ә көндез инде ачык түбәле абзарларга һавага чыгарылалар.

Ферма работниклары терлекләрне бервакытта да ялгыз калдырмыйлар. Төнлә дә 3—4 тапкыр чыгып, аларның хәлен белеп, күзәтеп торалар. Менә шундый катлаулы һәм җаваплы эш белән комсомолка иптәш Баһаветдинова җитәкчелек итә.

М. СӨНГАТУЛЛИНА.

АГИТАТОР СӘКИНӘ

Сәкинә Салаватова колхоз хисапчысының ярдәмчесе булу белән бергә, колхозчылар арасында танылган агитатор да. Ат караучылар Сәкинәнең килгәнен күрү белән:

— Әнә безнең комсомолка сеңлебез, Сәкинә килә,—дип яратып каршылыйлар һәм барысы да аның тирәсенә җыелалар. Сәкинәнең газета укуын игътибар белән тыңлыйлар. Беседаларда актив катнашалар.

Менә Камалиев Шәйхетдин бабай. Ул карт инде, аның колагы начар ишетә. Шуңа күрә ул беседадан соң Сәкинә янына килеп:

— Кызым, мин ишетеп бетерәдем әле, безнекеләр кайсы шәһәрне алганнар, кабатлап әйт әле, балам, —дип сорый. Билгеле, Сәкинә, бер дә авырсынмыйча, Шәйхетдин бабай белән аерым беседа үткәрә. Аңа атларны яхшы карауның фронтка ярдәм булуын аңлата. Шәйхетдин бабай да аңа картларча рухланып җавап бирә:

—Мин карый торган атлар 10 ысы да таза. Алар арасында 4 бия бар. Мин алардан менә дигән сылу колыннар алып, аларны җитез атлар итеп үстереп бирермен, —ди. Шулай итеп, агитаторның беседасы ат караучыларны тагын да яхшы эшләргә туплый.

Фронт айлыгы башлангач, ат караучылар язгы чәчүгә кадәр барлык атларны тазарту буенча яңа йөкләмәләр алдылар. Бу, билгеле, комсомолка агитатор Сәкинә Салаватова хезмәтенең нәтиҗәсен күрсәтә.

КОМСОМОЛ ЭШЧӘНЛЕГЕ

«КИМ» колхозы комсомол оешмасы үзенең 12 членын фронтка озатты, ләкин комсомол сафы аңарга карап кимеми. Ул алдынгы колхозчы яшьләр исәбенә үсә. Соңгы көннәрдә генә дә 3 кыз комсомолка исемен алды.

Биредә комсомолецлар тырыш һәм булдыклылар. Алар колхозның җаваплы участокларында эшлиләр. Яшь кыз Рабига Баһаветдинова—ферма мөдире, фронтовик Садретдинов—колхоз хисапчысы, Исмәгыйлов—бригадир, Салаватова—уку өе мөдире.

Фәйзуллина, Хайруллина һәм башка тагын берничә кыз сабан сөрү һәм чәчү эшләренә өйрәнәләр.

Күптән түгел комсомолецлар язгы чәчүгә әзерлек буенча эшләнгәннәргә йомгак ясау, киләчәктә тагын нәрсәләр эшләү турында сөйләштеләр. ВЛКСМ Өлкә Комитетының 7 нче пленумы карарлары аларга бу мәсьәләдә маяк булды. Комсомолецлар карарларны яхшылап өйрәнделәр һәм үзләренең эшләрендә булган җитешсезлекләрне тәнкыйтьләделәр.

Сүз, күбрәк, тәрбиягә мохтаҗ булган атларны шефка алу, агротехника укуларын дәвам иттерү һәм агрочараларның кышкы планын үтәү турында барды. Алдагы бурычлардан чыгып йөкләмәләр алынды:

— ВЛКСМ Өлкә Комитетының VII пленумы карарларын үтәү йөзеннән, 15 нче мартка кадәр һәрбер комсомолецка 50 килограмм көл, 20 килограмм кош тизәге җыярга. Бу чара буенча өмә оештырырга һәм һәрбер комсомолецның сабан сөрергә өйрәнүенә ирешергә.

— Атна саен әзерләнгән чәчүлек орлыкларның сакланышын карарга һәм аларның тишелешен тагын бер кат тикшерергә.

Сүз бирдеңме, эшләргә, йөкләмә алдыңмы, үтәргә кирәк бит. Егет сүзе бер булыр,—диделәр комсомолецлар. Һәм икенче көнне үк Кече Болгаер авылының һәрбер яшь егете һәм эшчән кызы үз хуҗалыкларында көл һәм кош тизәкләре җыю өчен уңайлы урыннар әзрләде. Билгеле, союздан тыш яшьләр дә комсомолецларга иярделәр.

— Чынлап керешсәң, бер көнлек эш бу, минем бригадамдагы яшьләр барысы да көл һәм кош тизәге җыялар,—ди 3 нче бригада җитәкчесе, булдыклы егет Зәки Шәйхетдинов. Комсомолец Исмәгыйлов бригадасы белән ярышып эшлиләр алар.

Шулай итеп, комсомол инициативасы колхозчы яшьләр арасына бик тиз күчте. Колхоз производствосының арттарак калып бара торган участокларында комсомол эшчәнлеге, яшьлек дәрте сизелеп торды. «КИМ» колхозының яшь хуҗалары язгы чәчүгә әзерлекне тәгәлләүне шактый тизләттеләр. Хәзер бу колхоз язгы чәчүгә ни-гездә әзер инде.

Н. МӘГЪСУМӘ.



Ростов-Дон бүген. Ростсельмашның күп кенә цехлары төзекләндерелде һәм эшли башлады. РӘСЕМДӘ: механика цехы.
ТАСС фотохроникасы

ИРТӘГӘ СМОТР БАШЛАНА

Беренче апрельдән 10 на кадәр колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның чәчүгә әзерлеген тикшерү үткәрелә. Бу эштә киң җәмәгатьчелекнең катнашыуын тәэмин итик!

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

БРИГАДА ИСЕМЕН АКЛЫЙ

Цехка килеп керү белән һәркемнең күзе стенадагы зур плакатка төшә. Анда эре-эре хәрефләр белән «Кичә стахановчы Ляля Кәбирова 220 урынына 340 деталь эшләп тапшырды», дип язылган.

Бу зур уңыш турында сөйли. Моннан берничә атна гына элек бригада членнарыннан берәү дә нормасын үти алмый иде.

— Безгә бу операцияләрне яхшылап үзләштерергә, нормаларны тулысынча үтәргә бик вакыт, —диде бригадир иптәш Арбузов.— Әйдәгез, бөтен көчебезне куеп эшлик, бер генә кеше дә нормасын үтәмичә тынычланмасын.

Бригада, Май алды ярышына чыгып, үзен фронт бригадасы итеп игълан итте. Бу исемне аклар өчен фронттагыча эшләргә кирәк. Моны һәркем аңлый.

Бригада членнарына аерым станоклар беркетелде. Бу хәл станокның төзеклеге һәм чисталыгы өчен җаваплылыкны тагын да арттырды. Станок ватылып, эштән туктап тору фактлары шактый кимеде. Шуның нәтиҗәсе буларак, хезмәт җитештерүчәнлеге сизелерлек рәвештә күтәрелә башлады.

Беркөнне иптәш Мельникова эштә күп кенә брак ясады, смена нормасын үти алмады. Ни өчен? Үзенең игътибарсызлыгы өчен. Аның турында киңәшмәдә генә сөйләнеп калмады, цех стенасындагы плакатка да язылып куелды. Бу хәл аңа бик нык тәэсир итте. Икенче көнне үк ул, башкалардан калышмаска теләп, тырышып эшләде һәм әйбәт кенә күрсәткечләр бирүгә иреште.

Хәзер бригадада нормасын үти алмаган бер генә кеше дә юк. Бригада смена нормасын уртача алганда 105—110 процентка үтәп бара. Аерым иптәшләрдән Лобашева норманы 136, Ключникова 125, Морозова—110 процентка үтиләр.

ПОЕЗДЛАР КЫЗУ ЙӨРИ

23 нче мартта Әгерҗе депо бүлегенең паровозчылары күрше юллар өчен гаять мөһим маршрутлар алып бардылар. Машинист Ваһапов эстафета поезды белән бер рейсны үрнәк төстә үткәрде. Маршрутның уртача тизлеге тәүлеккә 1.190 километрга җитте. Бу поездны алып баручылар составында булган баш кондуктор Кунгуров һәм поезд-вагон мастеры Бусыгина иптәшләр эштә зур тырышлык күрсәттеләр.

Машинист Бубнов һәм баш кондуктор Лепихин иптәшләр дә Май алды ярышында алдынгылык өчен уңышлы көрәшәләр. Алар бер эстафета поездын тәүлеккә 1.000 километр тизлектә алып бардылар. Әгерҗе депосы кривоносчыларыннан Бакеев һәм Бакаев иптәшләр дә поездларны тиз йөртү буенча соңгы көннәрдә зур гына уңышларга ирештеләр.

КЫРГА ЧЫГАРГА ӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

Безнең МТС ның 19 тракторы ремонттан чыкты инде. Тагын 4 тракторга ремонт тәгәлләнеп килә. Шушы көннәрдә тагылма инвентарьларны да төзәтеп бетерәбез.

Авыл хуҗалыгы машиналарын хәрәкәткә китерү өчен үз эшен яратып башкаручы, булдыклы кадрлар кирәк. Алар да бездә җитәрлек. Аларны хәзердән үк бригадаларга бүлеп, трактор һәм башка машиналарны беркетеп куйдык. МТС та барысы 10 трактор отряды оештырылды. Аларның өчесе хатын-кызлардан гына тора.

Бригадирлар һәм тракторчылар, партиябез һәм хөкүмәтебезнең таләпләреннән чыгып, язгы һәм җәйге кыр эшләре вакытындагы бурычлар белән яхшылап таныштылар. Үзара ярыш договорлары төзеп, конкрет йөкләмәләр алдылар. Менә иптәш Лесинков бригадасы. Аның бригадасында 3 трактор бар. Икесе дизелле, берсе «СХТЗ» тракторы. Дизель тракторы өчен план 957 гектар. Бу тракторда эшләүчеләр планны 1.250 гектарга җиткереп үтәргә сүз бирделәр. «СХТЗ» тракторында эшләүчеләр дә 360 гектар урынына 600 гектар сөрергә йөкләмә алдылар. Бу бригада үзе белән ярышка иптәш Ветлугина бригадасын чакырды.

9 нчы бригадада тракторчылар барысы да хатын-кызлар. Бирдәге кызлар 1942 нче елгы кыр эшләрендә нормаларын арттырып үтәгәннәр иде. Быел да алар 600 әр гектар эшләргә әзерләнәләр.

Һәрбер бригадада агитаторлар бар. Алар өчен 10 көнлек семинар үткәрелде.

Хәзер һәрбер бригада вагон, су савытлары, ягулык саклау урыннары әзерли. МТС та күчмә мастерской оештырыла.

Ф. ТӨХФӘТУЛЛИНА,
Мәлки МТС ның политбүлек начальнигы урынбасары.

Колхозларның оборона фондына

106. Гыйззәтуллина Ф.—Актаныш районы, «Изаил» колхозы члены—18 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

107. Садыйков М. — Актаныш районы, «Изаил» колхозы члены, 75 яшьлек карт, өч фронтовик атасы—25 пот ашлык бирде.

108. Гәрәев С.—Актаныш районы, «Красный пахарь» колхозы члены—25 пот ашлык бирде.

109. Евдокимова Н. — Актаныш районы, «Красный пахарь» колхозы члены—21 пот ашлык бирде.

110 Ялалов Ә. — Актаныш районы, «Красный пахарь» колхозының элекке председателе, хәзер Заготскот управляющие—61 пот ашлык бирде.

ЯРЫШТА АЛДЫНГЫЛЫК ӨЧЕН

Казан МТМ ы эшчеләре коллективы, Беренче Май алды ярышына кушылып, конкрет йөкләмәләр алдылар һәм үзләре белән ярышка Арча МТМ ы коллективын чакырдылар.

Ремонтта эшләүчеләр Беренче Май бәйрәме хөрмәтенә эшне бик нык яхшыртырга булдылар. Алынган йөкләмәләрдә комбайн моторларына ремонтны 1 нче апрельгә 105 процент итеп тәгәлләргә, запас частьлар әзерләү буенча планны 105 процентка, иске частьларны реставрацияләүне 115 процентка үтәргә, ягулык һәм майлау материалларына, төсле металлга 5 процент экономия ясарга дигән пунктлар бар.

Хәзер ярышта алдынгылык алу өчен каты көрәш бара. Ремонтта эшләүче иптәш Ильин көндәлек заданиене 170 процентка, иптәш Розанков 150 процентка үти. Өйрәнчек Гобәйдуллин дә норманы 150 процентка башкара.

Г. ГАЗИЗУЛЛИН.

БЕЗНЕҢ КАДРЛАР

Каргалы МТС ы 1942—43 нче елда 78 тракторчы, 5 бригадир, бер механик әзерләргә тиеш иде. Хәзер МТС та укучы 88 тракторчының 46 сына чыгарыш ясалды инде. Калганнары курста укуны дәвам итәләр. Бригадирлар курсында 3 кеше бригадирлыкка укып кайтты. Механиклар курсында 3 кеше укый. 9 кеше комбайнчы булырга әзерләнә.

МТС механизатор кадрлар әзерләү эшенә, ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомының хатын-кызлардан тракторчылар әзерләүне көчәйтү чаралары турындагы карары нигезендә, тракторлар үткән җәй кыр эшендә эшләгән вакытта ук керештe. Дирекция һәм политбүлек, тракторчы булырлык хатын-кызлардан 48 кешене сайлап алып, трактор отрядларына һәм аерым тракторчыларга өйрәнчек итеп беркетте. Алар җәйге кыр эшләре вакытында ук трактор янында практик эшкә өйрәнә башладылар. Кыр эшләреннән бушагач та, бу иптәшләр МТС янында тракторчылар курсында укырга керештеләр. Курста укучы 88 кешенең 44-е тракторда өйрәнчек булып эшләгән кешеләр. Прицепщик булып эшләгән иптәшләрдән «Динамо» колхозыннан гына да 8 кеше курсны отлично һәм яхшы билгесенә үзләштерде.

Курста укыган иптәшләр, мастерскойда эштә катнашып, ремонт эшендә дә практик күнегүләр алдылар. Алардан 34 кеше Дарья Гармаш бригадасы тракторчыларының чакыруы нигезендә тракторчы хатын-кызларның Бөтенсоюз социалистик ярышына кушылдылар, 1943 нче елгы сезонда эшләү өчен конкрет йөкләмәләр алдылар.

Хәзер 1943 нче елгы эш сезонында да тракторчылар әзерләүне дәвам итү өчен узган ел прицепщик булып эшләүчеләрдән 60 кеше сайлап алу эшенә керештек.

Х. ХӘБИРОВ.

Бер колхозның череп таркалган җитәкчеләре һәм чара күрмәүче район оешмалары турында

Балык башыннан чери, дигән әйтем Тукай исемендәге колхоз җитәкчеләренә карата бик туры килә. Бу колхозда соңгы бер ел эчендә генә дә 5—6 председатель алмашынган. Аларның һәрберсе эшлексезлек күрсәткән, хуҗасызлыкка, иясезлеккә, җинаятьләргә юл куйган, яисә үзе шуңа турыдан-туры катнашкан.

Шунысы гаҗәп, колхозны таркату хәленә китергән бу җинаятьчеләрнең берсе дә суд җаваплылыгына тартылмаган. Биектау районының суд-прокуратура органнары аларга карата килешүчәнлек күрсәткәннәр.

Колхозда хисап эшләре буталып беткән. Шуның аркасында колхоз милкен урлауларга турыдан-туры юл куелган. Менә фактлар. Дәүләткә бал тапшырудан килгән 743 сум акча кассага кермәгән. Завхоз Исмәгыйлов Галиәхмәт, үзенең шул эштә булуыннан файдаланып, колхозның 2 центнер 88 килограмм бодай онын, 10 килограмм итен Казанга илтеп саткан, акчасын кассага кайтармаган. Колхозчы Хуҗи Исмәгыйловка саклау өчен бирелгән 312 центнер бәрәңгенең дә кая киткәнлеге билгеле түгел. Узган елны яшелчә уңышының күпме булганлыгы һәм аның кайда тотылганлыгы турында да документ юк.

Колхоз хисапчысы Разия Сафина, төрле ялган документлар ясап, колхозның 87 килограмм онын, 2 килограмм балын, 4 килограмм итен, 10 килограмм икмәген һәм башка продуктларын урлаган.

Колхоз амбарыннан атларга дип җибәрелгән 18 центнер 61 килограмм ашлыкны Казанга илтеп сатканнар. Аның акчасы күпме булганлыгы һәм нәрсәгә тотылганлыгы турында хәзерге көнгә кадәр билгеле түгел. Аннан соң, 64 килограмм бал, 36 килограмм майның кая киткәнлеге турында да учет юк. Завхоз Исмәгыйлов, без аны колхозчыларга һәм районнан килгән вәкилләргә түләүсез бирдек, ди.

Председатель Җиһаншин, правление члены Исмәгыйлов Хуҗи, завхоз Исмәгыйлов Галиәхмәт эчеп-исереп йөргәннәр.

Колхоз җитәкчеләренең череп таркалган булулары нәтиҗәсендә, аерым колхозчылар арасында колхоз милкенә кул сузучылык таралган, дисциплинасызлык урын алган. Мәсәлән, Сәгъдиева Бибинур, Гарипова Фатима, Вафин Юнус һәм башкалар (барлыгы 24 кеше) колхоз саламын урлаганнар. Аларның эше тикшерү органнарына бирелсә дә, бу көнгә кадәр бернинди чара күрелмәгән. Эшкә соңга калып чыгу, иртә кайту, яисә бөтенләй эшкә бармау кебек фактлар гадәткә кереп киткән. Шакирова, Насибуллина, Сибгатуллина, Хәйретдинов, Хәйретдинова С., Җиһаншина, Салабакиналар бер хезмәт көне дә эшләмәгәннәр. Шулай булуга да карамастан, аларга карата авыл хуҗалыгы артеле уставы нигезендә чара күрелмәгән.

Колхозның язгы чәчүгә әзерлеге өзеклектә. Быел ул барлыгы 1.117 гектар җир чәчәргә тиеш. Шуның бары 306 гектарына гына җитәрлек орлык әзерләнгән. Тәрбия җитмәү, ерткычларча файдалану нәтиҗәсендә, колхоздагы 123 баш атның да шактый өлеше бөтенләй сафтан чыккан.

Терлекчелек фермасында да шундый охшашлы җинаятьләр тулып ята. Терлек үрчетү буенча колхозга бирелгән 1942 нче елгы план үтәлмәгән. Шулай ук, дәүләткә терлекчелек продуктлары тапшыру буенча бу колхозның бурычы күп әле. Мәсәлән, дәүләткә план буенча 17.000 данә урынына бары 7.800 данә йомырка, 25.700 литр урынына 9.730 литр гына сөт тапшырылган. Ферма мөдире Әгъзамовның, бригадир Зиннуровның, сыер савучылардан Галимова һәм Җәләеваларның, сарык караучылардан Зәйнетдинова һәм Хәмидуллиналарның үз эшләренә җавапсыз караулары аркасында 1942 нче елда бик күп терлек үлгән. Бу эштә гаеплеләрдән беркем дә җавапка тартылмаган. Алар хәзерге көндә дә әле тыныч кына шул урыннарында «эшләп» яталар.

Биредә культура көчләре байтак. Тулы булмаган урта мәктәптә генә дә 7 укытучы бар. Алар барысы да кәгазьдә агитатор булып исәпләнәләр. Фактта исә укытучы иптәш Степановадан башкалары колхозда масса-аңлату эшләрен бөтенләй алып бармыйлар. Уку йорты кәгазьдә генә яши. Клуб бер елдан бирле инде ябык. Комсомол оешмасы секретаре Мәрьям Шәмсетдинова да күбрәк сөйләнеп йөрү белән генә канәгатьләнә, комсомолецларның колхоз производствосында алдынгылык күрсәтүләре өчен көрәшми. Стена газетасы онытылганда бер тапкыр гына чыгарыла. Критик материаллар белән чыккан стена газетасын ертып ташлау кебек фактлар да бар. Мәсәлән, газетаның быел чыккан беренче номерында Исхаковның атларны кирәкмәс урынга җигеп йөрүе һәм кыйнавы турында материал урнаштырылган. Исхаков бу материалны газетадан алып ертып ташлаган. Бу самодурга карата да бернинди чара күрелмәгән. Газетаның быел чыккан өченче номерында колхоз хисапчысы Сафинаның колхозда учет эшләрен бутап бетерүе турында тәнкыйть материал урнаштырылган булган. Бу материал да шулай ук икенче көнне үк юкка чыккан.

Колхозны бөтенләй таркалуга алып бара торган югарыда күрсәтелгән фактлар район оешмаларына күптәннән билгеле булган. Бу турыда шул колхоз членнарыннан телдән дә һәм шулай ук язма рәвештә дә район оешмаларына сигналлар да килгән. Шулай ук район җитәкчеләре бу колхозда үзләре дә еш кына булганнар. Ләкин барлык кимчелекләр яшерелеп киленгән һәм аларны бетерү буенча конкрет бернәрсә дә эшләнмәгән.

Югарыда китерелгән фактлардан нинди нәтиҗә ясарга кирәк соң? Мәсьәлә ачык, комментарий таләп ителми. Тукай исемендәге колхозны кичекмәстән аякка бастырырга кирәк. Район җитәкчеләре дә һәм шулай ук район прокуроры да Тукай исемендәге колхоздагы хәлләрдән күз йомып килгәннәр икән, бу эш белән, һичшиксез, республика прокуроры кызыксыныр һәм гаеплеләрне каты җавапка тарту чараларын күрер, дип уйлыйбыз.

Р. ӘХМЕТШИНА,
«Кызыл Татарстан» ның махсус хәбәрчесе.
Биектау районы.

Югары уку йортларының студентлары, сугыш көннәрендә илебезнең җәмагать тормышында да актив катнашалар, укуның югары сыйфаты өчен көрәшне аз гына да киметмиләр.
РӘСЕМДӘ: Казан авиация институтының 3 нче курсы студенткасы, уку отличнигы иптәш Т. Ашина.

К. Тахтеев фотосы.

СУГЫШЧЫЛАР СЕМЬЯСЫНА ХАЛЫК ЯРДӘМЕ

Совет кешеләрендә семьяга мәхәббәт көчле. Ватан сугышы, туган илне ярату тойгысын арттыру белән бергә, семьяга булган мәхәббәтне дә көчәйтте. Тормышның кадерен белеп яшәргә, җылы кочагына сыендырып үстергән атаананы хөрмәтләргә, хезмәттә киңәшче, тормышта сердәшче булган иптәшеңне тагын да ныграк яратырга, киләчәкнең өметле чәчәкләре булган балаларны тагын да көчлерәк сөеп тәрбияләргә өйрәтте. Фронтовик каты сугыш вакытында да үзенең семьясын, туганнарын онытмый. Үзенең тормышын аларның рәхәт яшәүләре өчен кызганмый. Сугышчының чал сакаллы карт этисе:

— Улым коралга аптырамасын, тук булсын, киеме җылы булсын,— дип, үзенең хезмәтен аңа багышлый. Нинди генә эштә булса да, нәрсә генә эшләсә дә колхозчы яки эшче хатын, һәркөн эшләгән үзенең эшен:

— Балаларымның атасы сугышта исән йөрсен, минем тырышлыгым фронтта аның эшен җиңеләйтсен, —дигән хисләр белән башлый.

Яшьле күзләрен сабыйларча мөлдерәтеп этисен фронтка озаткан бала мәктәп бусагасын:

— Яхшы укыйм, этием кайткач мактасын,—дип атласа, өйләренә:

—Әнием ялгыз, аңа булышыйм,— дигән уй белән кайта. Менә шушындый ялкынлы патриотлар тәрбияләп үстергән илнең һәрбер кешесе:

— Фронт өчен тагын нәрсә эшләргә кирәк дигән мөкатдәс теләк белән яна.

Сугышчыларның семьясы турында кайгырту, аларга булышу да менә шушы мөкатдәс теләкнең чынбарлык чагылышы. «Искра» колхозының (Буа районы) чын патриотлары җыелышта:

— Фронт өчен барысын да эшләп тә, сугышчылар семьясына ярдәм оештырмау зур кимчелек булыр иде. Авылыбыздагы һәрбер семья безнең күз алдыбызда. Без аларга ничек һәм нәрсә белән ярдәм итәргә кирәклеген белеп торабыз, — диделәр.

Биредә колхозчылар дәүләт ярдәменнән тыш, кызылармеец семьялары өчен колхозда махсус фонд оештырдылар. Бу фондка авылның намуслы кешеләреннән иптәш Хәлиуллин 3 пот ашлык, 6 пот бәрәңге, 20 литр сөт һәм 500 сум акча кертте. Фәхретдинов һәм Вәлиев иптәшләр 3 әр пот ашлык, 6 шар пот бәрәңге һәм 500 әр сум акча бирделәр. Тиз арада, хәрби хезмәттәгеләрнең семьяларына ярдәм фонды өчен 60 пот ашлык, 50 килограмм йон, 100 центнер терлек азыгы, 15 бәрән һәм бик күп бәрәңге җыелды.

«Искра» колхозы членнары фронтовик авылдашларының семьяларын тәэмин итү белән бергә, район күләмендә дә махсус фонд төзү тәкъдимен кертеп, барлык колхозчыларга мөрәҗәгать иттеләр һәм үзләре бу фондка 40 пот ашлык, 130 пот бәрәңге, 112 литр сөт, 4.800 сум акча бүләк иттеләр. Искралылар инициативасы «Маяк», «Коминтерн» һәм Сталин исемендәге колхозларга да күчте. Аларда да шундый ук фондлар төзелде һәм район фондына да шактый күп байлык тупланды. Оборона Халык Комиссариатының приказы буенча оештырылган дәүләт комиссиясе чынлап эшкә керешге. Кызыл Армиягә батыр уллар үстергән картлар, карчыклар, ирен фронтка озатып берничә бала белән, вакытлыча ялгыз калган аналар, алар турында халыкның кайгыртуын күрделәр һәм күп кенә матди ярдәм алдылар. Бу хәл аларның күңелен күтәрде. Шуңа күрә дә Толымбай авылы мәктәбенең 3 нче классында укучы кечкенә кыз Зәкия Галләмова әбисенең чын күңелдән әйткән сүзләрен этисенә язды:

«Безнең турыда борчылма. Илең һәм авылдашларың безне рәхмәтеннән ташламый.»

М. НУРЕТДИНОВА.

Каникул күңелле үтте

Башлангыч һәм урта мәктәпләрдә язгы каникуллар бүген, 31 нче мартта тәмам була. Каникул көннәрендә мәктәпләрдә әдәбият, концерт кичәләре оештырылды. Театрларда балалар өчен сеанс спектакльләр бирелде, Ленин музей йортына, бөек ватан сугышы трофейлары күргәзмәсенә һәм башка әһәмиятле урыннарга походлар үткәрелде, төзү ату һәм шахмат ярышлары оештырылды.

— Молотов районының Белинский исемендәге урта мәктәбе язгы каникулны зур уңышлар белән каршылады. Анда укучылар 3 нче чиректә 92 процент өлгереш бирделәр. Укучыларының 64 проценты төп фәннәр буенча отлично һәм яхшы билгеләре алдылар. 3 нче чиректә отлично һәм яхшы билгеләре генә алган укучыларның саны 33 процентка кадәр күтәрелде.

Язгы каникуллар вакытында мәктәптә балалар өчен төрле күңел ачу кичәләре оештырылды. Өлкән классларда укучылар хәрбиләштерелгән походта катнаштылар. Мәктәптә Пушкин әсәрләреннән әдәби-музыкаль кичә ясалды. Бүген 8—10 классларда укучылар катнашы белән төз ату ярышлары үткәреләчәк.

— Ватан сугышы фронтларында немец илбасарларга каршы каты сугыш дәвам итүгә карамастан, безнең мәктәпләребездә һәм балалар учреждениеләрендә культура тормышы бер генә минутка да тукталмый. Казанда ачылган Пионерлар һәм мәктәп балалары йорты балаларга оешкан төстә культура хезмәте күрсәтүдә аеруча күренекле урын тота. Анда ял көне сәен лекторий эшләп килә. Атаклы кешеләр турында һәм төрле фәнни темаларга лекцияләр һәм сәнгать кичәләре үткәрелә. Пионерлар йортында оештырылган балет, драма, уйлап табу, тегүчитү, гимнастика түгәрәкләрендә һәм башкаларда 600 гә якын бала катнаша.

Язгы каникуллар вакытында Пионерлар йортында һәркөн үзешчәнлек сәнгать кичәләре оештырылды, кино-сеанслар бирелде. Шәһәрнең 15, 20, 83 нче һәм башка мәктәпләре үзләрендә укучылар өчен анда концерт кичәләре һәм кече яшьтәге балалар өчен түгәрәкләр оештырдылар.

Апрель аенда Пионерлар йортында «Рус партизаннары», «Химия сугышы», «Планеталарда тереклек бармы?» һәм «Йокы һәм төш күрү» темаларына лекцияләр һәм шул темаларга карата музыка бүлекләре оештырылачак. Лекцияләрне укырга академиклар һәм тәҗрибәле профессорлар чакырылды. 14 нче апрельдә яшь тамашачылар театры артистлары белән балаларның очрашу кичәсе үткәреләчәк.

Англия, Америка һәм Франция гаскәрләренең алга баруы

ЛОНДОН, 29 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы союзниклар гаскәрләренең Тунис фронтының һәммә участокларында да һөҗүм алып баруларын хәбәр итә. Англиянең 8 нче армиясе частьлары Эль-Хамманы алганнар һәм хәзер Роммельнең төп порты һәм базасы булган Габестан 16 миль ераклыкта торалар.

Гафса—Макнасси районында хәрәкәт итүче Америка гаскәрләре һәм Англиянең 8 нче армиясеннән көнбатыштарак хәрәкәт итүче француз частьлары Кайруанга таба баралар. Кайруаннан 20 миль ераклыктагы Фондукны алган Америка гаскәрләре колонна-сы тар буена килеп чыкканнар.

Тунисның төньягында Англиянең 1 нче армиясе тимер юлларның әһәмиятле узелы булган Җәбәл-Абиода районында һөҗүм башлаган һәм уңышлы рәвештә алга бара. Союзниклар гаскәрләре фронтның барлык участокларында да җирдә һәм һавада өстенлек алганнар.

Лондон газеталарының хәрби хәбәрчеләренең язуына караганда, хәзер немец гаскәрләренең Габес районыннан чигенүләре өчен яр буендагы тар бер коридор гына калган. Габеска таба һөҗүм 4 яклап: Эль-Гаттардан, Макнассидан, Фаид аралыгыннан килә торган юлдан һәм Фондуктан килә торган юлдан алып барыла. Әгәр дә немецлар калган тар коридордан чигенү өчен файдаланмасалар, ул чагында аларның чигенү юлы тиздән киселергә мөмкин.

ГЕРМАНИЯ ПЛЕННЫЙЛАРЫ АРАСЫНДА ВОССТАНИЕ

НЬЮ-ЙОРК, 29 март, (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Германиядәге хәрби пленныйлар һәм ирексезләп Германиягә китерелгән чит ил эшчеләре арасында восстаниеләр башлану турында ышанычлы хәбәрләр алынган. Меңнәрчә хәрби пленныйлар һәм эшчеләр предприятиеләрдән качалар һәм оешкан группалар төзиләр. Союзниклар авиациясенең Германия шәһәрләренә һөҗүмнәре вакытында бу группалар аеруча актив хәрәкәт итәләр.

Регуляр полиция частьлары бу отрядларга каршы тора алмыйлар. Гитлерчылар юлларны саклау өчен махсус отрядлар төзергә мәҗбүр булганнар.

Хәрби пленныйларның концентрация лагерьларыннан тоташ группалар булып качу вакыйгаләре һаман арта. Качкан чакта алар, гадәттә, лагерь сакчыларын үтереп, үзләре белән кораллар алып китәләр.

АМЕРИКАНЫҢ «ЛАЙФ» ЖУРНАЛЫНЫҢ СССР ГА БАГЫШЛАНГАН МАХСУС НОМЕРЫ

НЬЮ-ЙОРК, 29 март. (ТАСС). Америкада киң күләмдә таралган «Лайф» журналы издательствосы бөтенләе белән Советлар Союзына багышланган махсус номер чыгарды. Журнал 116 биттән тора. Тышында иптәш Сталин рәсме бар.

Журнал практикасында аерым бер илгә багышланган мондый махсус номерның беренче тапкыр чыгарылуын аңлатып, редакция «күтәрле рус халкына ихтирам белән тулган дусларча соклануын белдерергә һәм Советлар Союзының казанышлары белән яхшырак танышуда Америка укучыларына ярдәм итәргә» теләгәнлеген яза. Журналда: «Шундый аз гына вакыт эчендә бер генә ил дә әле мондый гаять зур нәтиҗәләргә беркайчан да ирешә алганы юк иде», — диелгән.

Журналда промышленностьның, фәннең, культураның, әдәбиятның һәм сәнгатьнең барлык өлкәләрендә Советлар Союзы ирешкән казанышлар турында күп төрле материаллар бар.

Күп кенә мәкаләләр Кызыл Армиянең фашист урдаларга каршы героик көрәшенә багышланган

Грециянең министрлар кабинеты составында үзгәреш

ЛОНДОН, 29 март. (ТАСС). Таймс газетасының язуынча, Каһирәдә Греция короле Георг һәм баш министр Цудерос белән Грециянең политик әшлекләләре, партияләр вәкилләре һәм Грециянең кораллы көчләре вәкилләре арасында булган сөйләшүләр нәтиҗәсендә Грециянең министрлар кабинеты составында үзгәрешләр булган. Хөкүмәт Якын Көнчыгышта калырга уйлый.

ҺАВА СУГЫШЫ

ЛОНДОН, 29 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 24 нче мартка каршы төндә Англия бомбардировщиклары Сен - Назерда Германия су асты көймәләр базасына бик зур һөҗүм ясаганнар.

Англиянең 8 нче армиясе Габесны алган

ЛОНДОН, 30 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының тапшыруына караганда, Черчилль, Англиянең 8 нче армиясе бүген иртә белән Габес аша үтте, дип белдергән.

Англия гаскәрләре ныгытылган Марет линиясен алганнар

ЛОНДОН, 29 март. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, 8 нче армия, 26 нчы мартта дошман позицияләренә каршы башланган атакасын дәвам иттереп, дошманны ныгытылган Марет районыннан чигенергә мәҗбүр иткән. Авиациянең көчле һәм бик нәтиҗәле ярдәме белән барган бу сугышларда союзниклар гаскәрләре дошманның бик күп кешеләрен, танкларын, орудиеләрен һәм мототранспортын юк иткәннәр.

Хәзер Марет линиясендәге төп ныгытмалар барысы да союзниклар армиясе кулында. Кичә алар Марет, Тужан һәм Матмата пунктларын алганнар. Соңгы 8 көн эчендә 6.000 нән артык кеше пленга алынган.

Англия авиациясенең Берлинны бомбага тотуының нәтиҗәләре

ЛОНДОН, 29 март. (ТАСС). Авиация министрлыгының хәбәр итүенчә, 28 нче мартка каршы төндә Берлинны бомбага тоту 30 минут дәвам иткән. Шәһәргә 1.800 һәм 3.600 килограмм авырлыктагы бик күп бомбалар ташланган. Шпрее елгасының ике ягында да киң мәйданда зур янгыннар күренгән.

Берлинга ясалган һөҗүм сугыш башланганнан бирле Лондонга ясалган һөҗүмнәрдән шактый зуррак булган. Лондонга ясалган иң көчле һөҗүм 1941 нче елның 17 нче апреленә каршы төндә булган иде. Ул вакытта Лондонга кимендә 450 тонна бомба ташланган иде. 28 нче мартка каршы төндә исә Берлин өстенә аңа караганда ике тапкыр чамасы күбрәк бомбалар ташланган.

Композитор Рахманинов үлгән

НЬЮ-ЙОРК, 28 март. (ТАСС). Бүген Лос-Анжелос шәһәрендә (Калифорния) күренекле рус композиторы Сергей Рахманинов 70 яшендә үлде.

ХРОНИКА

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы иптәш К. В. Даньконы Татарстан АССР коммуналь хуҗалык халык комиссары итеп билгеләде.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

ТЕАТРЛАРДА ҺӘМ КИНОЛАРДА

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 6 нчы апрельдә—**«Хуҗа Насретдин».**

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген—**«Ильдар»,** 1 нче апрельдә—**«Патша кәләше».**

Зур драма театры. Бүген — **«Украина далаларында»,** 1 нче, 2 нче апрельдә **«Рус кешеләре».**

Яшь тамашачылар театры. Бүген — **«Финист—ясный сокол».** көндез 1 сәгатьтә һәм кич 7 сәгатьтә башлана.

Дәүләт циркы. Бүген өч бүлектә **зур цирк тамашасы.** Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татарстан дәүләт филармониясе. Бүген Менжинский исемендәге клубта **комедияләр кичәсе.** Кич 8 сәгать 30 минутта башлана.

«Электро»—көндез — **«Партизаннар Украина далаларында»,** кич— **«Сталинград».** «Унион»—**«Партизаннар Украина далаларында».** «Пионер» — көндез—**«Руслан һәм Людмила»** һәм— **«Боксерлар»,** кич— **«Дуслык».** «Чаткы»—**«Моряк кызы».**

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—73—27, Редактор урынбасары АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре 78—93, типография 36—60.

ПФ 109 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 587